# И С Т Ә Л Е К

(بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ)

/Бисмилләһир-рахмәнир-рахы́м/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ Тәгалә исеме белән барча яхшы эшләребезне башлыйбыз. Аллаһ ошбу дөньяда бөтен кешеләргә рәхмәтен бирә, мөселманнарга да, кәферләргә дә. Әмма Ахирәттә фәкат мөселманнарга гына рәхмәтен бирәчәк”.

Коръәндә әйтелгән: Әш-Шүра Сүрәсе, 11-нче Аять:

قَالَ اللهُ تَعَالَى: (لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَىْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ البَصِير)

/Ләйсә кәмислики́ шәй-ү-үә һүәс-сәми́‘уль-бәсы́рь/

*Мәгънәсе:* “Аллаһка берни дә охшамас, Ул һәр нәрсәне ишетүче вә һәр нәрсәне күрүче” (күрүе – күз белән түгел, ишетүе – колак белән түгел).

Имам Тәкыюд-Дин Әс-Сүбкий шул сүзләрне әйткән булган:

{الْعِبَادَةُ أَقْصَى غَايَةِ الْخُشُوعِ وَ الْخُضُوعِ}

/Әль-‘ыбә́дәтү акса́ га́ятүль-хушу́‘ үәль-худу́‘/

*Мәгънәсе:* “Гыйбәдәть – Аллаһка иң бөек дәрәҗәле табыну вә буйсыну”. Гыйбәдәтнең тагын бер мәгънәсеннән: иң бөек дәрәҗәле табыну вә буйсыну нияте белән кеше маңгаен җиргә кую – бу эшне фәкать Аллаһка кылырга ярый, башкасына кылса – кешене Диндән чыгара. Әмма Аллаһтан башкасыннан сорарга, ялварырга, чакырырга ярый. Ул Аллаһтан башкасына гыйбәдәт итү түгел, ширк түгел.

Хәнәфи мәзһәбенең галимы Имам Әбү Җә‘фәр Әт-Тахәуий шулай әйткән булган:

{تَعَالَى عَنِ الْحُدُودِ وَ الْغَايَاتِ وَ الأَرْكَانِ وَ الأَعْضَاءِ وَ الأَدَوَاتِ لاَ تَحْوِيهِ الْجِهَاتُ السِّتُّ كَسَائِرِ الْمُبْتَدَعَاتِ}

/Тә‘а́лә́ ‘аниль-худу́ди үәль-га́я́т үәль-эрко́ни үәль-а‘да́-и үәль-әдәүә́т,
лә́ тәхуи́һил-җиһә́түс-ситти кәсә́-ириль-мүбьтәдә‘а́т/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ шундый сыйфатлардан пакь (өстен): киртәләр, гаятьләр, почмаклар, әгъзалар (зур һәм кечкенә органнар). Аллаһка алты тараф (як) кушылмас, һәм әйтелмәс, чөнки тарафлар мәхлүкатьләргә генә әйтелә”.

Имам Әгъзам Әбү Хәнифә әйтте:

{وَ اللهُ وَاحِدٌ لاَ مِنْ طَرِيقِ الْعَدَدِ وَ لَكِنْ مِنْ طَرِيقِ أَنَّهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ}

/ҮәЛлә́һу үә́хидун лә́ мин тари́кыль-‘адад үә
лә́кин мин тари́къ аннаһү лә́ шәри́кә ләһ/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ – Бер сан исәбе белән түгел, әмма – тиңдәше һәм уртагы булмаганын аңлата”.

Имам Әбүл-Хәсән Әл-Әш‘арий “Ән-Нәүәдир” китабында шулай әйткән булган:

{مَنِ اعْتَقَدَ أَنَّ اللهَ جِسْمٌ فَهُوَ غَيْرُ عَارِفٍ بِرَبِّهِ وَ أَنَّهُ كَافِرٌ بِهِ}

/Мән-итәкадә эннәЛлә́һә җисмүн фәһүә гайру
‘а́рифин бираббиһи́ үә эннаһү́ кә́фирун биһи́/

*Мәгънәсе:* “Кем: “Аллаһ – җисем”, – дисә, ул Аллаһны белми вә кәфер, ышанмаган була”.

Имам Әхмәд Әр-Рифә‘ый әйтте:

{غَايَةُ الْمَعْرِفَةِ بِاللهِ الإِيقَانُ بِوُجُودِهِ تَعَالَى بِلاَ كَيْفٍ وَ لاَ مَكَانٍ}

/Га́ятүль-ма‘рифәти биЛлә́һиль-и́ка́н
би-вүҗү́диһи́ Тә‘а́лә́ билә́ кәйфин үә лә́ мәкә́н/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ турында иң бөек белем – һич шиксез Аллаһның урынсыз һәм кәйфиятсез барлыгына ышану”.

Имам ‘Алий ибн Әбү Талиб әйткән сүзләрен Әбү Мәнсур Әл-Бәгдәдий “Әл-фәрку бәйнәл-фирак” китабында итте:

{إِنَّ اللهَ خَلَقَ الْعَرْشَ إِظْهَارًا لِقُدْرَتِهِ وَ لَمْ يَتَّخِذْهُ مَكَانًا لِذَاتِهِ}

/ИннәЛлә́һә халякаль-‘аршә изһа́ран ликудратиһи́ үә
ләм яттахизһү мәкә́нән лизә́тиһи́/

*Мәгънәсе:* “Дөреслектә Аллаһ Тәгалә Гаршны Үз Кодрәтен күрсәтер өчен яралтты, вә Үзенә урын итеп алмады”.

Имам Мәлик вә Имам Зүн-Нүн Әл-Мисрий әйткән булганнар:

{مَهْمَا تَصَوَّرْتَ بِبَالِكَ فَاللهُ بِخِلاَفِ ذَلِكَ}

/Мәһмә́ тәсаүүәртә бибә́ликә фәЛлә́һү бихилә́фи зә́ликә/

*Мәгънәсе:* “Күз алдыңа нәрсә булса да китерәлсәң, Аллаһ бернигә дә охшамас”.

Имам ‘Алий ибн Әбү Талиб әйткән иде:

{مَنْ زَعَمَ أَنَّ إِلَـهَنَا مَحْدُودٌ فَقَدْ جَهِلَ الْخَالِقَ الْمَعْبُودَ}

/Мән зә‘амә эннә Илә́һәнә́ мәхду́д фәкад җәһиләль-
Ха́ликаль-ма‘бу́д/

*Мәгънәсе:* “Кем: “Аллаһның чикләре бар”, – дисә, ул Аллаһны белмәгән кәфер була”.

Имам Әбү Җәгфәр Әт-Тахәүий шулай әйтте:

{وَ مَنْ وَصَفَ اللهَ بِمَعْنًى مِنْ مَعَانِي الْبَشَرِ فَقَدْ كَفَرَ}

/Үә мән үәсафәЛлә́һә бимә‘нән мин мә‘а́ниль-бәшәр фәкад
кәфәр/

*Мәгънәсе:* “Кем Аллаһка мәхлүкатьләрнең сыйфатларыннан бер сыйфатны кушса – кәфер була”.

Имам Әбү Хәнифә һәм Әл-Бухарий әйткән иделәр:

{فِعْلُهُ تَعَالَى صِفَةٌ لَهُ فِي الأَزَلِ وَ الْمَفْعُولُ حَادِثٌ}

/Фи‘лүһү́ Тә‘а́лә́ сыфатүн ләһү́ филь-әзәли үәль-мәф‘у́лү хә́дис/

*Мәгънәсе:* “Аллаһның фигыйле – Аның мәңгелек Сыйфаты, әмма мәфгул (нәтиҗә) – мәхлүк (яралтылган)”.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Украина, Киев шәһәре, Лукьяновская урамы, 46. тел. (8-044) 465-18-77, 465-18-78

Имам Әбү Бәкр Әс-Сыддик әйткән сүзләрне Бәдруд-Дин Әз-Зәркәший риваять итте:

{الْعَجْزُ عَنْ دَرَكِ الإِدْرَاكِ إِدْرَاكٌ وَ الْبَحْثُ عَنْ ذَاتِهِ كُفْرٌ وَ إِشْرَاكٌ}

/Әл-‘аҗзү ‘ан дәракиль-идра́ки идра́кү үәль-бәхсү

‘ан зә́тиһи́ куфрун үә ишра́күн/

*Мәгънәсе:* “Аллаһны төшенеп булмауны, зәгыйфлегебезне аңлау – үзе иман. Ә кем Аллаһка берәр шикел, охшаш кушса – кәфер була” (Аллаһ турында уйлау көфергә китерә, әмма мәхлүкатләр турында уйлау – иманны көчәйтә).

Имам ‘Алий ибн Әбү Талиб әйткән иде:

{كَانَ اللهُ وَ لاَ مَكَانَ وَ هُوَ الآنَ عَلَى مَا عَلَيْهِ كَانَ}

/Кә́нәЛла́һү үә лә́ мәкә́н, үә һуәл-ә́нә ‘аля́ мә́ ‘аләйһи кә́н/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ бар иде, урын юк иде, вә Аллаһ урынны яралтканнан соң да үзгәрмичә урынсыз бар”.

Имам ‘Алий ибн Әбү Талиб әйткән сүзләреннән шул:

{الْيَوْمَ الْعَمَلُ وَ غَدًا الْحِسَابُ}

/Әл-яүмәль-‘амәлү үә гадәниль-хисә́б/

*Мәгънәсе:* “Бүген гамәл, иртәгә – хисап”. Дөньяда гамәл бар, әмма хисап юк, әмма Ахирәттә – хисап булачак, гамәл булмас.

Имам ‘Абдүл-ГанийӘн-Нәбүлсий шулай әйтте:

{مَنِ اعْتَقَدَ أَنَّ اللهَ مَلأَ السَمَوَاتِ وَ الأَرْضَ أَوْ أَنَّهُ جِسْمٌ قَاعِدٌ فَوْقَ الْعَرْشِ فَهُوَ كَافِرٌ وَ إِنْ زَعَمَ أَنَّهُ مُسْلِمٌ}

/Мәни‘тәкадә эннЛла́һә мәлә-әс-сәмә́үә́ти үәль-әрда әү эннәһу́ жисмүн ка‘идүн фәүкаль-‘Арши фәһүә кә́фирун үә ин зә‘амә эннәһу́ мүслим/

*Мәгънәсе:* “Кем: “Аллаһ күкләрдә урын алган, я дә җирләрдә Ул, я дә Гарш өстендә утырган җисем”, – дигән булса, ул – кәфер була, үз үзен мөселман диеп исәпләсә дә”.

Имам Кадый ‘Ияд әйткән:

{لاَ خِلاَفَ أَنَّ سَابَّ اللهِ تَعَالَى مِنَ الْمُسْلِمِينَ كَافِرٌ}

/Лә́ хилә́фә эннә сә́ббәЛла́һи Тә‘а́лә́ минәль-мүслими́нә кә́фир/

*Мәгънәсе:* “Мөселманнар арасында хилафсыз билгеле: Аллаһны хурлаган, сүккән кеше – шиксез кәфер”.

Имам Әбү Хәнифәнең “Әл-Үәсыят” китабында шулай әйтелгән:

{مَنْ قَالَ بِحُدُوثِ صِفَاتِ اللهِ أَوْ شَكَّ أَوْ تَوَقَّفَ فَهُوَ كَافِرٌ}

/Мән кәлә бихүдү́си СыфәтиЛлә́һи әү шәккә әү тәүәккафә фәһүә кә́фир/

*Мәгънәсе:* “Кем: Аллаһның Сыйфатлары мәңге түгел, башлана, я дә бетә, – дисә, шикләнсә, аптырап тукталса – кәфер була”.

Имам Мүхәммәд Әл-Газәлий шулай дигән:

{لاَ تَصِحُّ الْعِبَادَةُ إِلاَّ بَعْدَ مَعْرِفَةِ الْمَعْبُودِ}

/Лә́ тәсыххүл-‘ыбә́дәтә иллә́ бә‘дә мә‘рифәтиль-мә‘бу́д/

*Мәгънәсе:* “Кемгә гыйбәдәть кылганын белмәгән кешенең гыйбәдәте кабул булмас.” Аллаһны белмәгән кешенең гыйбәдәте кабул булмас.

Имам Әбү Хәнифә әйткән иде:

{أَنَّى يُشْبِهُ الْخَالِقُ مَخْلُوقَهُ}

/Әннә́ юшбиһүл-Ха́лику мәхлү́каһү/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ – Яралтучы һич Үз мәхлүкатьләренә охшамас”.

Пәйгамбәребез Мүхәммәд салляллаһү ‘аляйһи үә сәлләм әйткән:

قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: "كَانَ اللهُ وَ لَمْ يَكُنْ شَيْءٌ غَيْرُهُ وَ كَانَ عَرْشُهُ عَلَى الْمَاءِ وَ كَتَبَ فِي الذِّكْرِ كُلَّ شَيْءٍ ثُمَّ خَلَقَ السَّموَاتِ وَ الأَرْضَ" رَوَاهُ الْبُخَارِيّ

/Кә́нәЛла́һү үә ләм якүн шәй-үн гайруһу, үә кә́нә ‘Аршүһу́ ‘аләль-ма́-и үә кәтәбә физ-зири күллә шәй-ин сүммә халякас-сәмә́үә́ти үәль-әрд/

*Мәгънәсе:* “Аллаһ мәңге бар иде, Аллаһ мәхлүкатләрен яралтканча берни юк иде. Аллаһ башта суны яралтты, аннан соң Әл-Гаршны яралтты, соңыннан Кыямәт көненә кадәр булачак нәрсәләр язылды, соңра Аллаһ күкләрне һәм җирне яралтты”. Шушы Хәдисне Имам Әл-Бухарий риваят итте.

Имам Әбү Сүләймән Әл-Хаттабий шулай әйткән:

{إِنَّ الَّذِي يَجِبُ عَلَيْنَا وَ عَلَى كُلِّ مُسْلِمٍ أَنْ يَعْلَمَ أَنَّ رَبَّنَا لَيْسَ بِذِي صُورَةٍ وَ لاَ هَيْئَةٍ فَإِنَّ الصُّورَةَ تَقْتَضِي الْكَيْفِيَّةَ وَ هِيَ عَنِ اللهِ وَ عَن صِفَاتِهِ مَنْفِيَّةٌ}

/Иннәлләзи́ яҗибү ‘аляйнә́ үә ‘аля́ күлли мүслимин эн я‘лямә эннә Раббәнә́ ляйсә бизи́ су́ратин үә лә́ һәй-этин фә-иннәссу́ратә тәктәдыль-кяйфийяһ үә һия ‘аниЛля́һи үә ‘ан сыфә́тиһи манфийяһ/

*Мәгънәсе:* “Безгә вә һәр мөселманга белү тиешле булган нәрсәләрдән шул: Аллаһ җисемсез вә кыяфәтсез, чөнки җисемнең шикеле була, әмма Аллаһка вә Сыйфатларына шикел ләек түгел, Аллаһ шикелсез вә кәйфиятсез”.

Коръәндә әйтелгән: Әл-Ихләс Сүрәсе, 4-нче Аять:

قَالَ اللهُ تَعَالَى: (وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ)

/Үә ләм якүлләһу́ куфүән әхәд/

*Мәгънәсе:* “Аллаһның тиңдәше вә охшашы юк”.

---

Украина мөселманнары Диния идарәсе
Украина, Киев шәһәре, Лукьяновская урамы, 46. тел. (8-044) 465-18-77, 465-18-78